КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 27

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 август, 733 нче; 2019 ел, 23 сентябрь, 871 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенең 5.2 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 пункты» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту

тәртибенең 5.4 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 пункты» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 8 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш фаразларын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенең 5.1 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 пункты» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 8 пункты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин